| | | |
|---|---|---|
| **ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

11 апрель 2014ел Казан шәһәре № 10-10/кс

***ҖЧҖ «БиоТранс» татарфыннан күрсәтелгән каты көнкүреш калдыкларын зарарсызландыру, утилизацияләү һәм күмү хезмәте өчен тарифларны билгеләү турында***

“Коммуналь комплекс оешмалары тарифларын җайга салу нигезләре турында” 30 декабрь, 2004 ел, № 210-ФЗ Федераль законга, “Коммуналь комплекс оешмалары эшчәнлеге өлкәсендә бәя кую нигезләре һәм тарифларны, өстәмәләрне һәм чик индексларны җайга салу тәртибе турында” 14 июль, 2008 ел, № 520 Россия Федерациясе Хөкүмәте карарына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 15 июнь, 2010 ел, № 468 карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмәгә туры китереп, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга № 1 кушымта нигезендә, ҖЧҖ «Био транс» тарафыннан күрсәтелә торган каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү, зарарсызландыру һәм күмү хезмәте күрсәтүгә тарифны календарь бүленеш нигезендә билгеләргә.

2. Бу карарның 1 пунктында билгеләнгән тариф 2014 елның 1 июненнән 2017 елның 31 декаберенә кадәр үз көчендә була.

3. Бу карарның 2 пунктында күрсәтелгән тарифның гамәлдә булу чорына, № 2 кушымта нигезендә, каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү, зарарсызландыру һәм күмү өлкәсендә ҖЧҖ «БиоТранс» производство программасының төп күрсәткечләрен килештерергә.

4. Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 30 декабрь, 2009 ел, № 1140 карары белән расланган мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә, чираттагы җайга салу чорына тарифны билгеләү турында карар кабул ителгәннән, соң 30 көннән дә соңга калмыйча ҖЧҖ «БиоТранс» халыкка җиткерелергә тиешле мәгълүматны ачарга тиеш.

5. Каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү хезмәте күрсәтүгә бу карарда билгеләнгән тариф “Коммуналь комплекс оешмалары товарларының һәм хезмәтләр күрсәтүләренең кулланучылар өчен куллану мөмкинлеге критерийлары системасын билгеләү турында” 24 февраль, 2014 ел, № 56 Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты боерыгы белән расланган коммуналь комплекс оешмалары товарларының һәм хезмәтләр

күрсәтүләренең кулланучылар өчен куллану мөмкинлеге критерийларына туры килә.

6. Түбәндәге карар рәсми нәшер ителгәннән соң ун көн узгач тулы көченә ия була.

Татарстан Республикасы
тарифлар буенча
дәүләт комитеты Рәисе
вазыйфаларын башкаручы А.Л. Штром

Татарстан Республикасы тарифлар
буенча дәүләт комитетының
11 апрель 2014 ел № 10-10/кс
карарына 1нче кушымта

ҖЧҖ «БиоТранс» татарфыннан күрсәтелгән каты көнкүреш калдыкларын зарарсызландыру, утилизацияләү һәм күмү хезмәте өчен тарифлар

| № п/п | Муниципаль берәмлек, коммуналь комплексы оешма исеме | Каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү, зарарсызландыру һәм күмү хезмәте күрсәтүгә тарифлар, сум./куб.м | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 1 июнь 2014 ел - 30 июнь 2014 ел | 1 июль 2014 ел - 31 декабрь 2014 ел | 1 январь 2015 ел - 30 июнь 2015 ел | 1 июль 2015 ел - 31 декабрь 2015 ел | 1 январь 2016 ел - 30 июнь 2016 ел | 1 июль 2016 ел - 31 декабрь 2016 ел | 1 январь 2017 ел - 30 июнь 2017 ел | 1 июль 2017 ел - 31 декабрь 2017 ел |
| | Ютазы муниципаль районы | | | | | | | | |
| 1 | ҖЧҖ «БиоТранс»* | 114,94 | 121,60 | 121,60 | 122,87 | 122,87 | 131,31 | 131,31 | 131,31 |

<*> гадиләштерелгән салым алу системасы кулланыла

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының тариф
чишелешләрен кабул итүне оештыру,
контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы тарифлар
буенча дәүләт комитетының
<u>11 апрель 2013 ел № 10-10/кс</u>
карарына 2нче кушымта

## ҖЧҖ “Био Транс” тарафыннан каты көнкүреш калдыкларын үтилизацияләү, зарарсызландыру һәм күмү өлкәсендә җитештерү программасының төп күрсәткечләре

| № п/п | Коммуналь комплексы оешмасының исеме | 1 июнь 2014 ел - 31 декабрь 2014 ел | | | | | 1 гыйнвар 2015 ел - 31 декабрь 2015 ел | | | | | 1 гыйнвар 2016 ел - 31 декабрь 2016 ел | | | | | 1 гыйнвар 2017 ел - 31 декабрь 2017 ел | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Коммуналь комплексы оешмасының җитештерү программасы күрсәткечләре, мең.куб.м | | | | Кирәкле тулай керем, мең сум. (ӨБС керми) | Коммуналь комплексы оешмасының җитештерү программасы күрсәткечләре, мең.куб.м | | | | Кирәкле тулай керем, мең сум. (ӨБС керми) | Коммуналь комплексы оешмасының җитештерү программасы күрсәткечләре, мең.куб.м | | | | Кирәкле тулай керем, мең сум. (ӨБС керми) | Коммуналь комплексы оешмасының җитештерү программасы күрсәткечләре, мең.куб.м | | | | Кирәкле тулай керем, мең сум. (ӨБС керми) |
| | | Каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү күләме, шул исәптән: | | | | | Каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү күләме, шул исәптән: | | | | | Каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү күләме, шул исәптән: | | | | | Каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү күләме, шул исәптән: | | | | |
| | | Барлыгы | Кулланучылар | Бюджеттагы кулланучылар | Башка кулланучылар | | Барлыгы | Кулланучылар | Бюджеттагы кулланучылар | Башка кулланучылар | | Барлыгы | Кулланучылар | Бюджеттагы кулланучылар | Башка кулланучылар | | Барлыгы | Кулланучылар | Бюджеттагы кулланучылар | Башка кулланучылар | |
| 1 | ҖЧҖ «Био-Транс»* | 24,00 | 17,894 | 2,1014 | 4,0496 | 2859,27 | 24,00 | 17,894 | 2,1014 | 4,0496 | 2929,67 | 24,20 | 18,049 | 2,1014 | 4,0496 | 3076,57 | 24,20 | 18,049 | 2,1014 | 4,0496 | 3177,70 |

<*> гадиләштерелгән салым алу системасы кулланыла

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының тариф
чишелешләрен кабул итүне оештыру,
контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге